# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 11 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12; 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 41 статьяның өченче һәм алтынчы абзацларын үз көчен югалткан дип танырга;

2) $53^4$ статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

3) $60^1$ статьяның 2 пунктында "Россия Федерациясе бюджет системасы" сүзләрен "Татарстан Республикасы бюджет системасы" сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 17 статьясындагы 2 пунктының, 18 статьясындагы 2 пунктының, $53^1$ статьясындагы 2 пунктының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12; 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш) гамәлдә булуын 2013 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**3 статья**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2006 елның 11 декабрендәге 76-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 8);

2) "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2007 елның 2 августындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 30 пунктының дүртенче абзацын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 8; 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш);

3) "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2008 елның 3 октябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш);

4) "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләрен куллану тәртибе турында" 2009 елның 3 декабрендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 12 (I өлеш);

5) "Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2011 елның 18 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 13 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 11 (I өлеш);

6) "Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2011 елның 30 ноябрендәге 95-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 1 пунктының "б" пунктчасын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 11 (II өлеш).

**4 статья**

1. Әлеге Закон, шушы Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан, 3 статьясындагы 1 – 3, 6 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты, 3 статьясындагы 1 – 3, 6 пунктлары 2013 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2012 елның 2 ноябре
№ 74-ТРЗ